12+
DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы **24** июнь, **2016** ел № 4 (149)




• Игнат – Нижневартовскидан килгән абитуриент. Руслан Бушков фотосы.

# Киләчәгеңне бүгеннән төзе!

Әгәр синең сәләтең, һөнәри һәм тормыш амбицияләрең ташып торса, барлык максатларыңа ирешәсең, үзеңне көчле шәхес итеп тәрбиялисең һәм танытасың килә икән, Казан федераль университеты нәкъ менә сине көтә!

## АЛМАШЫП УКУ

21 нче июнь көнне И.Кант исемендәге Балтыйк федераль университетында Россия югары уку йортлары ректорлары очрашуы булып узды. **И.Гафуров** катнашкан әлеге чарада Россия һәм Германия югары уку йортлары арасында алмашып уку мәсьәләләре хәл ителде. Шулай ук алмашып уку вакытында барлыкка килә торган сораулар һәм вузларга бирелә торган квота мәсьәләләре дә каралды.

## PRO НАУКА

28 июнь көнне Казан федераль университеты **«PRO Наука в КФУ»** дип исемләнгән ачык фәнни-популяр чаралар сериясен башлап җибәрәчәк. Университет мәйданчыкларында беренче тапкыр теләгән һәркем өчен фәннигамәли лекция, интерактив остаханәләр, тәҗрибә, эксперимент, уеннар оештырылачак. Моннан тыш төрле лаборатория һәм музейлар да һәркем өчен ачык булачак.

## СТИПЕНДИАТЛАР БИЛГЕЛЕ

Күптән түгел генә КФУ Попечительләр советы стипендиатлары билгеле булды. Стипендиатларның берсе – Исәпләү математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының Математик статистика кафедрасы аспиранты **Искәндәр Кареев**. Искәндәр статистик эшчәнлекне тикшерә һәм бүгенге көндә статистик анализ ясауның яңа методикасын эшли икән.




# АБИТУРИЕНТЛАР ЧОРЫ

**Раил САДРЕТДИНОВ**

БУ КӨННӘРДӘ МӘКТӘПЛӘРДӘ БЕРДӘМ ДӘҮЛӘТ ИМТИХАННАРЫ ТАПШЫРЫЛА. «ТАТАР-ИНФОРМ» МӘГЪЛҮМАТ АГЕНТЛЫГЫНДА КФУ РЕКТОРЫ ИЛШАТ ГАФУРОВ ҺӘМ УНИВЕРСИТЕТНЫҢ КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕНЕҢ ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИБЕ СЕРГЕЙ ИОНЕНКО КҮПЛӘРНЕ БОРЧЫГАН СОРАУЛАРГА ҖАВАП БИРДЕЛӘР.

Илшат Гафуров билгеләп узганча, бүгенге көндә Россиянең 74 субъектыннан инде гариза бар. «Без илнең бөтен территориясен колачлыйбыз. Ерак һәм якын чит илләрдән дә студентлар байтак». Аның сүзләренә караганда, былтыр өч имтихан буенча уртача балл 76,4 тәшкил иткән. Бу бик югары балл. Узган ел КФУ университетлар арасында БДИ буенча иң югары балларга ия булган һәм Россиядә классик университетлар арасында 4 нче урынга чыккан иде. Ректор КФУга керү өчен кирәкле баллның күләмен әйтү әлегә иртәрәк булуын билгеләп узды. Әмма 60 тан да ким балл җыйган студент кабул ителмәячәк, диде.

«Бүген фундаменталь медицина һәм биология белгечлекләренә ихтыяҗ арта. Элеккечә, юриспруденция, икътисади белгечлекләр популяр кала. IT-технологияләр буенча яңа белгечлек барлыкка килде. Анда да конкурс саллы булачак. Физика һәм Химия институтлары да күпләрне кызыксындыра. Гомумән алганда, соңгы биш елда коммерция шартларында кабул итү буенча план күрсәткечләрен үтәмәгән бер генә институт та булмады, шуңа күрә кайсыдыр юнәлешне аерырга теләмәс идем. Чит ил әдәбияты, лингвистикага, халыкара мөнәсәбәтләр институтына да конкурс зур», — дип сөйләде Илшат Гафуров.

Уку йортында түләүле нигездә уку өчен иң түбән бәя педагогик белгечлек буенча 78 мең сум, ә иң кыйбатлысы 169 мең сумга (дәвалау эше) кадәр тәшкил итә. Тулы исемлек вузның рәсми сайтында басылган.

Бәяләргә килгәндә, Илшат Гафуров аларны формалаштыруга ачыклык кертте: «Ул РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы нормативыннан түбән була алмый, базар принцибын да исәпкә алып, бәя ихтыяҗ һәм тәкъдим нәтиҗәсендә формалаша», — дип белдерде.

Ә Сергей Ионенко КФУга Бердәм дәүләт имтиханын бирмичә кереп була торган очракларга ачыклык кертте. «Россия гражданнарына килгәндә, алар — сәламәтлеге буенча БДИ бирмәүчеләр яки инвалидлар, урта яки югары һөнәри белем турында дипломы булганнар, чит ил гражданнары. Әгәр дә сез Россия гражданлыгына ия, ә белем турында документны чит илдә алгансыз икән, сез шулай ук эчке сынаулар гына бирәсез. Бу нормалар вузга кабул итү кагыйдәләренә кертелгән», — диде җаваплы сәркатип.

Абитуриентларның БДИ нәтиҗәләре буенча балларына өстәмә баллар алу мөмкинлеге турында да әйтелде. Мәсәлән, алтын медаль ияләренә 5, университет яки Идел буе төбәк күләмендәге олимпиадаларда җиңгән өчен 2 шәр балл һәм ГТО алтын значогы өчен 1 балл өстәлә икән.

Илшат Гафуров бу уку елына 5316 бюджет урыны булуын хәбәр итте. «Шуны билгеләп үтәргә кирәк: бюджет урыннарының саны РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы игълан иткән конкурс шартлары нигезендә билгеләнә. Анда югары уку йортының белем бирү программалары сыйфаты, инфраструктурасы, профессор-мөгаллимнәр составы, эш тәҗрибәсе һәм башка күрсәткечләр исәпкә алына».

Очрашу азагында ректор иң уңышлы бизнесменнарның 50 проценттан артыгы КФУны тәмамлаучылар булуын ассызыклады. «Без чыгарылыш студентлары лаеклы эш хакы түләнә торган урыннарга урнаша алырлык белем бирергә тиеш», — диде Илшат Гафуров.

**Мәгълүмат «Татар-информ» МА алынды.**

# КФУда ЯҢА КООРДИНАЦИОН СОВЕТ

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫ ПРОГРАММАЛАРЫ КЫСАЛАРЫНДА МИЛЛИ МӘДӘНИЯТНЕ САКЛАУ МЕТОДИКАСЫН БУЛДЫРУ ҺӘМ СӘЯСИ-МӘДӘНИ БЕЛЕМ БИРҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ӨР-ЯҢА, УНИКАЛЬ КООРДИНАЦИОН СОВЕТ ОЕШТЫРЫЛАЧАК.

Әлеге карар КФУның 23 нче май көнне узган ректорат утырышында кабул ителде. Ректор **Илшат Гафуров** мондый Координацион совет булдыру кирәклеген күп тапкырлар искәрткән иде инде. Советның нинди булырга тиешлеген һәм эшчәнлегенең әзер планын Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры **Р.Р.Җамалетдинов** тәкъдим итте. Рәдиф Рифкать улы әйтүенчә, туган телләрне укыту, тел турындагы канунның үтәлешен тикшереп торуны нәкъ менә шул Совет башкарырга тиеш.

Сәяси-мәдәни белем, тәрбия бирү дигәндә, милли телләр белән чит телләрне өйрәнү арасында тәңгәллек урнаштыру күзаллана. Шул ук вакытта аерым фәннәрне һәм белем бирү программаларын татар телендә укыту методикасын булдыру да күздә тотыла. Аерым игътибар татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү мәсьәләләренә биреләчәк. Моның белән дә шушы Координацион совет шөгыльләнәчәк. Мәсәлән, ФМБИның Г.Тукай исемендәге Татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге нигезендә Г.Тукай исемендәге тюркология һәм татаристика Югары мәктәбе ачылыр дип көтелә. Югары мәктәп кысаларында «Татаристика», «Тюркология» һәм «Төрки халыклар мәдәнияте, сәнгате» кебек өр-яңа белем бирү программалары булдырылачак. Шул ук институтның Рус һәм чит илләр филологиясе бүлеге нигезендә Рус һәм чит илләр филологиясе Югары мәктәбе ачылачак һәм ул шулай ук әлеге Совет күзәтчелегендә эшләячәк. Болар белән беррәттән, Совет Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында милли тарихны өйрәнүне җайга салуга зур игътибар бирәчәк.

КФУ ректоры Илшат Гафуров бүгенге көндә татаристика юнәлеше югалмый гына түгел, киресенчә, үсеш кичерә дип белдерде. И.Гафуров татароведение кафедрасы урынына бөтен бер Югары мәктәп ачылачагын ассызыклады. Иң әһәмиятлесе: татаристика һәм тюркология Югары мәктәбе кысаларында әлеге юнәлешләрне өйрәнә торган берничә кафедра ачылачак. Мәсәлән, төрле мәдәни традицияләрне өйрәнүгә багышланган аерым кафедра булдыру планлаштырыла. *«Безнең федераль университет күп югары уку йортларын берләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Нәкъ менә шуңа күрә милли телләрне һәм мәдәниятне өйрәнү эше бер ноктада туплана алмады. Хәзер исә боларның барысын да бер институт кысаларына берләштерү мөмкинлеге бар. Мөгаен, бу эшчәнлек Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты кысаларында булыр. Мин үзем мондый Советны оештыру бик дөрес карар дип уйлыйм».*

---

# «АНА ТЕЛЕ» ОНЛАЙН-МӘКТӘБЕ

КФУда МЕДИЦИНА, ФИЗИКА, ХИМИЯ, ТЕЛЛӘР ДИСЕҢМЕ – КАЙСЫ ГЫНА ӨЛКӘНЕ АЛМА, ҮСЕШ ҺӘМ ФӘННИ АЧЫШЛАР ӨЧЕН МӨМКИНЛЕКЛӘР ЧИКСЕЗ.

Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында татар теленә өйрәтә торган «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшләп килә. Онлайн-мәктәп Россиядә, Татарстанда гына түгел, чит илләрдә яшәүчеләр өчен дә белем үзәге буларак хезмәт итә. Биредә җир шарының теләсә кайсы почмагында торып, тәүлекнең төрле вакытында белем алып була. Онлайн-мәктәп фонетика, лексика, грамматика һәм сөйләү практикасы буенча дәресләр бирә. Күнекмәләрен арттырырга теләүчеләр өчен видеофильмнар да тәкъдим ителә.

«Ана теле» онлайн-мәктәбен камилләштерү максатыннан, лингафон кабинетлары да булдырылган. Берничә укытучы, бер үзәктә утырып, дәресләр бирә ала. Бер дәрескә 6 укучы керә. Татарстанның ерак бер авылы, Мәскәү, Алабуга һәм Америка вәкилләре бер үк вакытта, бер үк укытучы белән шөгыльләнә ала.

Онлайн-мәктәп белән генә чикләнергә теләмәүчеләр өчен, КФУ мөгаллимнәре бушлай 3 ай эчендә тел үзләштерү мөмкинлеген тәкъдим итә. Бирегә төрле яшьтәге кешеләр йөри ала. Милләт, белем, һөнәр — берсе дә әһәмияткә ия түгел. Иң мөһиме — татар телен өйрәнү теләге. Татар теле дәресләре, нигездә, кичке сәгатьләрдә уза. Курсларда укыту коммуникатив методика буенча алып барыла. Узган уку елында әлеге курсларга 800дән артык кеше язылган иде. Димәк, КФУ дөрес юнәлештә эшли.



# КФУ: Камил Фикерле Уңышлы

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ 200 ЕЛДАН АРТЫК ТАРИХЫ БАР. ШУШЫ ДИСТӘЛӘГӘН ЕЛ ЭЧЕНДӘ УКУ ЙОРТЫБЫЗ КҮП ҮСЕШ-ҮЗГӘРЕШ, ЯҢАЛЫКЛАР КИЧЕРГӘН.**



## 2015 ел

Г.В. Плеханов исемендәге Россия экономика университеты КФУ составына керде.





## 2012 ел

Апрель яңалыкларга бай булып чыкты. Инженерия академиясе федераль университет исемлегенә керергә теләк белдерде.







## 2011 ел

КФУ Финанслар һәм икътисад институты, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм Алабуга педагогика университетын үз канаты астына алды.



## 2010 ел

ТР Президенты аппараты каршында эшләп килгән Дәүләт хезмәте Академиясе һәм анда белем алган 1300 студент 2010 нчы елның июнендә КФУ белән берләште.

Бары алга барганда һәм үзгәрешләргә әзер булганда гына уңышка ирешергә мөмкин. Моннан берничә ел элек уку йортыбыз, федераль университет дәрәҗәсенә ирешеп, берничә уку йортын үз канаты астына алды. Икътисадның реаль секторында кирәкле һәм әһәмиятле булган белем һәм күнекмәләр бирү мөмкинлеге тагын да артты.

Әлеге үзгәрешнең нәтиҗәсе дә озак көттермәде. КФУ Идел буе регионында иң зур һәм иң көчле югары уку йорты санала. Биредә әһәмиятле фәнни ачышлар ясала һәм югары сыйфатлы белгечләр әзерләнә.

## Фактлар саннарда

45 000 СТУДЕНТ

3 200 ЧИТ ИЛ СТУДЕНТЫ

272 000 КВ. М СТУДЕНТ

415 ЛАБОРАТОРИЯ

3 430 АСПИРАНТ һәм МАГИСТРАНТ

8 000 КВ. М ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ТОРАГЫ

КФУ ӘКРЕНЛӘП ДӨНЬЯКҮЛӘМ АРЕНАДА ТАНЫЛГАН ИҢ ЯХШЫ УНИВЕРСИТЕТЛАР МОДЕЛЕНӘ ЯКЫНЛАША. БИРЕДӘ ФӘН БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ ӨЧЕН БӨТЕН МӨМКИНЛЕКЛӘР ДӘ БУЛДЫРЫЛГАН.

# УРТАК ҖИҢҮ

THE 301 - 350

THE 151 - 160 Europe

THE BRICS & EMERGING ECONOMIES RANKINGS 31

QS 551 - 600

QS UNIVERSITY RANKINGS BRICS 72

QS 335 “Arts and Humanities”

Times Higher Education Британия басмасы ясаган нәтиҗәләр буенча, Казан университеты 2015 нче елда дөньядагы иң яхшы уку йортлары исемлегенә керде. Гомуми диапазонда 301-350 нче, ә 18 Россия университеты арасында 4 нче урын – КФУ эшчәнлеге нәтиҗәсе.

«Фәнни басмалардан цитата алу» күрсәткече иң мөһим факторларның берсе һәм бәяләү аспектларының 30%ын тәшкил итә. Соңгы биш елда КФУ галимнәренең халыкара чыганакларда файдаланыла торган язмалары саны 5 тапкырга (280 нән 1543 кә) арткан.

КФУ предмет рейтингларында да югары баскычлар яулады. Мәсәлән, **World University Rankings** югары уку йортларының халыкара рейтингында Казан университеты 551-600 төркеменә керде, ә Россия уку йортлары арасында 12 нче урында тора. Университетыбызның башка федераль уку йортларыннан югарырак баскычта булуы – куанычлы күренеш.

**Round University Ranking (RUR)** – 2016 рейтингы буенча КФУ узган елдагы күрсәткечне 54 баскычка күтәрде. Быел Казан университеты дөньякүләм аренада 257 нче урында санала. Югары нәтиҗәләр университетның 2010 елда кабул ителгән Үсеш программасын тормышка ашыру эшчәнлегенә бәйле.

КФУ дөньяның 35 иленнән 185 югары уку йорты һәм фәнни үзәк белән хезмәттәшлек итә. Килешү нигезендә КФУ белән чит ил уку йортлары арасында 10-15 елга алмашып уку программасы кабул ителгән. Алар арасында: Ю.Либиг исемендәге Гиссен университеты (Германия), Фрайбург университеты (Швейцария), Инсбрук университеты (Австрия), Хельсинки университеты (Финляндия), Лондондагы Ричмонд Америка университеты (Бөекбритания), Тор Вергата Рим университеты (Италия), INALCO (Франция), Хунань педагогика университеты (Кытай), Пусан милли университеты (Көньяк Корея), Цукуба университеты (Япония), Питтсбург университеты (АКШ) һ.б.. Студентларга семестр яки бер уку елы дәвамында чит ил югары уку йортларында стажировка узу мөмкинлеге бирелә.

КФУда мәктәп укучыларына да ишекләр ачык. Бирелә **IT лицей-интернат** – КФУ базасында сәләтле балалар өчен оештырылган структур үзәк; **Кече Университет** – вузга кадәр белем бирү үзәге (укыту программасына лекцияләр, практик дәресләр, тренинглар һәм консультацияләр кертелгән); **Балалар Университеты** – проект 8 яшьтән алып 12 яшькәчә балалар өчен каралган, өйдә эти-әниләр аңлатып бирә алмаган һәм мәктәптә дә җавап табылмаган сорауларны үзенчәлекле лекцияләр ярдәмендә хәл итә; **Н.И.Лобачевский исемендәге лицей-интернат** – Россиянең булачак лидерларын тәрбияли, берьюлы берничә проектта катнашып, иҗади сәләтләрен үстереп, КФУ галимнәре белән берлектә фәнни тикшеренүләр үткәрә.



# ЯРАТКАН УКУ ЙОРТЫМ!

Айгөл АБДРАХМАНОВА

БЕЗНЕҢ УНИВЕРСИТЕТНЫ ТӘМАМЛАП, ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ЯШӘП ЯТУЧЫ МИЛЛӘТӘШЛӘРЕБЕЗ, ҮЗЛӘРЕНЕҢ СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫН САГЫНЫП, ХАТИРӘЛӘРЕ БЕЛӘН УРТАКЛАШТЫЛАР.

## Зөлфирә Сәгъдиева (Стокгольм, Швеция)



Әтнә районы Күлле-Киме мәктәбен тәмамлап, югары белемне Казан университетының физика факультетындагы астрономия бүлегендә алдым. Университетта укыганда, үзлектән төрек телен өйрәндем, инглиз телен камилләштердем. Укуны тәмамлагач, Казанда 5 ел инженер-математик булып эшләдем, соңрак Төркия фирмасына тәрҗемәче булып урнаштым. Язмышымны Швеция белән бәйләдем. Бүген дә биредә яшим. Стокгольм университеты каршындагы курсларда математика фәнен укытам. Туган як белән элемтәне өзмибез, елга бер булса да кайтып киләбез. Группадашлар белән очрашкалыйбыз, университет турында якты хатирәләр белән уртаклашабыз. Хәер, хәзер чит илдә дә яшәргә җиңел, чөнки ерактагы якын кешеләр белән аралашу өчен компьютер, телефон бар. Швециядә татарлар белән аралашабыз, бергәләп җырлар тыңлыйбыз. Татар концертлары килсә, аларны калдырмыйбыз.

## Алия Фәйзуллина (Питтсбург, АКШ)



КФУда уку елларын мин, һичшиксез, иҗат белән бәйлим: Татар халык хоры, Студентлар клубы, Студентлар язы. Биш еллык укуның иң якты мизгелләре актив студент тормышы белән бәйле.

Казан Федераль университетында хәзер студентларга бик күп мөмкинлекләр бар дип саныйм. Тырышсаң, төрле стипендияләр, грантлар отып була. Хәтта чит илдә укып кайту өчен дә бөтен шартлар булдырылган. Мин бик бәхетле студент идем, чөнки КФУ махсус стипендияләр биреп кенә калмады, хәтта җыр аранжировкалары өчен дә үзе түләде. Барысы да студентлар өчен!

Америкага күченгәч, бөтенләй башка һөнәр сайларга туры килде. Тик КФУда алган белем, иҗади тәҗрибә мине төрле сынауларга әзер шәхес итеп тәрбияләде.

КФУ, югары белем белән бергәләп, яхшы тормыш мәктәбе дә ул. Монда укып чыккан бер генә студент та югалып калмас дип саныйм.

## Диләнур Ахунҗанова (Җиде Пулат, Казахстан)



Казан дәүләт университетында уку минем өчен иң кызыклы һәм актив дәвер иде. Әнием дә шушы университетны тәмамлаган. Укырга кергәнче үк, истәлекләрен сөйләп, мине кызыксындыра иде. Ниһаять, хыялым тормышка ашты! Мин Казан дәүләт университетына укырга кердем. Яңа тормышка аяк басу, яңа дуслар, яңа укытучылар, башка дөнья, башка киңлекләр, мөмкинлекләр... Беренче көннән үк без бердәм төркемгә әвереләдек, бер-беребезгә һәрвакытта да ярдәм итәргә тырыштык.

Хәтерлим, зачет-имтиханнарга әзерләнгәндә, аерым бер көндә җыелып, бөтен сорауларны бергәләп карап чыга идек. Бергәләшеп имтихан барган аудитория ишеге алдында калтырап басып тора идек. Төркемебездә имтихан бирүнең ниндидер бер тәртибе дә бар иде: һәр зачет-имтиханга беренче булып төркемдәшебез Рашат керә, ә мин — һәрвакыт тәмамлаучы.

Ул УНИКСтагы репетицияләр дисеңме... Көнетөне шунда идек. Соңрак үзебез дә беренче курска кергән студентларны өйрәтә башладык. Кызык чаклар иде... Ниндидер аеруча зур энтузиазм да хөкем итте ул елларны: укудан да артта калмыйбыз, бөтен җирдә катнашырга да өлгерәбез. Төркемдәш кызлар белән җыелышып, «Just a dream» исемле рок төркеме дә оештырдык! Университетта уку дәверендә аерым бер урынны Татар халык хоры алып торды. КФУ хоры тырышлыгы белән мин татар халкының музыкасы, татарның моңы, рухының нәрсә икәнен аңладым. Университет ул белем йорты гына түгел. Университет — ул шәхес тәрбияли торган зур үзәк!

Әлбәттә, югары уку йорты кешене уңай якка үзгәртә, ә бай тарихлы Казан университетында уку сиңа әле чиксез күп мөмкинлекләр дә бирә! КФУ дигән шундый зур, дус «гаилә»нең «бала»сы булу — үзе олы бәхет!

# ӨМЕТЛЕ КАҺАРМАН

**Раил САДРЕТДИНОВ**

«БЕРӘҮ ЧИТ ТЕЛНЕ ӨЙРӘНӘСЕ БУЛСА, БАШТА ҮЗ ТЕЛЕН ЯХШЫ БЕЛСЕН» ДИП ЯЗГАН МӘГЪРИФӘТЧЕ-ЭНЦИКЛОПЕДИСТ КАЮМ НАСЫЙРИ. ӘЛЕГЕ ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘРНЕ ҮЗ ЭШ-ГАМӘЛЛӘРЕ БЕЛӘН ӨМЕТ ТӘ ДӘЛИЛЛИ СЫМАН.

Язмам герое – **Өмет Каһарман**, Кытайның Уйгыр автономияле районында туып-үскән уйгыр егете. Шулай булуга карамастан, ул, туган телебезне өйрәнергә дип, Казан федераль университеты Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегенә укырга керә.

Россия белән танышуны ул 2011 елда ерак Себердән башлый. Новосибирск шәһәрендә рус телен өйрәнү буенча әзерлек курсларында бер ел укыгач, Өмет серле Казан турында уйлана башлый. Ә Казан турында ул Кытайда вакытта ук ишетә.

*«Безнең китапларда, тарихи материалларда, дәреслекләрдә татарлар 19 нчы гасыр ахырыннан 20 нче гасыр башына хәтле Казаннан килеп, безгә мәгариф, фәнни яктан күп булышкан дип язылган. Безгә иң беренче мәктәп-хастаханә ачып биргән кешеләр ул татарлар. Шуңа, боларны ишеткәнгә, минем Казанга киләсем килде»*, – ди Өмет. Новосибирскида әзерлек курсларын тәмамлаганнан соң, ул интернетта Казандагы яшьтәшләре белән аралаша һәм, бирегә чакыру алганнан соң, ике дә уйлап тормыйча, 2012 елның сентябрендә Казанга килеп төшә. *«Килгәч тә, Казан шулкадәр нык ошады. Үземне Европаның бер шәһәренә килеп эләккәндәй хис иттем»*, – дип, хис-кичерешләре белән бүлешә Өмет.

Биредә ул тагын бер ел рус теленә әзерлек курсларында укый. Аны тәмамлаганнан соң, сайлау алдында кала: кайсы институтка керергә? Өмет

*Казан – өметләрем акланган шәһәр.*



КФУны сайлый. Татар телен шомартырга аның бүлмәдәше, 2005 елда Кытайдан килгән татар кешесе булыша. Өметнең социаль челтәрләрдә татарча аралашкан дусларына хатларны алар бергәләп яза. Өмет төркемендә беренче курста кытай татарлары да була. Алар татар алфавитын, хәрефләрен өйрәнәләр, татар теле дәресләренә дә йөриләр. Ә Өмет, рус телен өйрәнәм дип килгәнгә, андый мөмкинлектән мәхрүм кала. Шулай булуга карамастан, бер әзерлексез татар телен өйрәнә башлаган Өмет 2 ел эчендә телебезне камил белгән студентка әверелә. Бүген хәтта Казанда яшәгән татар балаларына караганда да яхшырак белә ул туган телебезне.

*«Казанга рус телен өйрәнергә дип килгән идем, әмма миңа татар теле дә кирәк булып чыкты. Чөнки Казанда булсын, башка авыл-районнарга барсам да, миңа татар теле кирәк буласын сиздем. Уйгыр теле дә татар теленә якын булгач, миңа авыр булмады, зур кызыксыну белән өйрәндем»*, – ди Өмет.

*КФУның татар филологиясе бүлеге минем өчен яңа мөмкинлекләр ачты, үз телемне, тугандаш татар телен тагын да ныграк ярата башладым, яңа дуслар таптым.*

Кытайда татарлар ничек яши, уйгырлар белән нинди мөнәсәбәттә дип кызыксынам. *«Кытайда 5000гә якын татар бар дип беләм,* – дип сөйләп китте Өмет. – *Аларның күпчелеге Шенҗан-Уйгыр автономияле районының Үремче, Чәүчәк, Колҗа шәһәрләрендә урнашкан. Алар шунда, мөселман халыклары белән бергә никахлашып, төпләнеп, матур гына яшәп яталар. Күбесе уйгырча сөйләшә. Урамнан барганда, татар белән уйгырны аерып булмый, бары тышкы кыяфәт кенә бераз аерыла. Чишмә авылында татарларның үз татар мәктәпләре бар. Анда татарчага төпле өйрәтәләр. Катнаш никахсыз булган татарларның теле Казан татарларыныкына охшамаган. Һәр милләт бергә бер гаилә булып яшибез. Бездә иң зур бәйрәм – Ураза, Корбан гаете. Аларны бергә үткәрәбез. Казанга килмәсәм, татарларда Сабан туе бәйрәме бар икәнен белмәс идем»*.

Өмет фикеренчә, үз телеңне белмәү – хурлык, начар хәл. Тел булмаса – милләт, милләт булмаса – тел юк. Өмет авызыннан яңгыраган әлеге хакыйкатьне күпләребез санга сукмый. Милләтне саклап калу өчен, телне саклап калырга кирәк, дип уйлый ул. *«Ике татар очрашып, русча сөйләшүчеләрне дә күрдем мин монда. Миңа бу хәл бик кызганыч булып тоелды»*.

Милләтебезне хөрмәт иткән Өметтән әңгәмәбез ахырында *«Татар кызына өйләнер идеңме?»* – дип сорадым. Баксаң, егетнең әти-әнисе каршы түгел. *«Әгәр ул кыз минем белән китәргә риза булса, мин дә каршы түгел?!»* – диде ул.

# Югары уку йортына ничек керергә?

**Фәнзия НУРУЛЛИНА** тәрҗемәсе

### Үз хокукларың турында исеңдә тот

Абитуриентның берьюлы бернечә югары уку йортына керергә хокукы бар. Барлык Рәсәй университетлары һәм академияләре (шул исәптән дәүләтнеке һәм коммерцияле) урта белем турындагы документларның расланган күчермәләрен кабул итәргә тиеш. Аларны теләсә кайсы нотариус расларга мөмкин. Иң мөһиме — бернечә уку йортына документлар тапшырганда, вакытны һәм үз көчегезне исәпләп, барлык имтиханнарга да өлгерә алачагыгызга тулысынча инанырга кирәк.

### Акча янчыгына үрелергә ашыкма

Дәүләт уку йортларында, «Мәгариф турында»гы канун нигезендә, документлар кабул итү, имтиханнар тапшыру тулысынча бушлай (шул исәптән коммерция нигезендә укырга керүчеләргә дә). «Канцелярия чыгымнарына» дип акча җыю законсыз рәвештә башкарыла. Дәүләтнеке булмаган уку йортларында исә, имтиханнар өчен түләү хакында уку



йорты һәм абитуриент арасында төзелә торган килешүдә язылырга тиеш.

### Алдакчылардан саклан

Таныш булмаган кешенең кабул итү комиссиясендә утыручы «үз» кешесенә түгәрәк суммадагы акча түләп, йөз процентлы керү тәэмин итәм дигән тәкъдименә ышанмаска киңәш ителә. Бу очракта сезне алдаулары бик ихтимал. Андый ятьмәләргә эләгеп, акча түләгәнче, түләүле бүлеккә керүең шактый очсызрак һәм ышанычлырак булыр. Акчагыз да югалмас, дәүләт дипломы да алырсыз. Егетләргә исә армиягә баруны кичектерү мөмкинлеге дә туа. Уку йортының һәм сезнең шәхси хокук-бурычларыгызны үз эченә алган язма рәвештә килешү дә төзергә онытмагыз.

### Льгота һәм өстенлекләр турында онытма

Бу бигрәк тә ятим балалар, балачактан инвалидлар, беренче, икенче төркем инвалидлары, кайнар нокталарда хезмәт иткән солдатларга һәм абитуриентларның тагын бернечә категориясенә кагыла. Бу төркемгә керүчеләр югары уку йортына бәйгедән тыш керә: имтиханнарда уңай бәя алу җитә. Шулай ук Рәсәй күләмендә һәм халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр дә аерым хокукларга ия. Халыкара олимпиада җиңүчеләре имтихансыз керә ала, калган җиңүчеләр исә уку йортының ничек хәл итүенә карап кабул ителә. Мәктәпне медальгә тәмамлаучыларга, училище, колледж һәм техникумны кызыл дипломга бетерүчеләргә, беренче курска керер өчен, белгечлек буенча бер имтиханны «бишле» билгесенә тапшыру да җитә.

---

АКЫЛ ФАБРИКАСЫ

## СЕЗНЕҢ ӨЧЕН

АКТИВ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕНӘ ҖӘЙ НИ ДӘ, КАНИКУЛ НИ. АЛАР ГЕЛ ХӘРӘКӘТТӘ, ПЛАННАРЫ ДА БЕРНИЧӘ АЙГА АЛДАН ТӨЗЕЛГӘН.

2016 нчы елның 4-7 август көннәрендә **Бөтендөнья татар яшьләре форумы «Акыл фабрикасы»** уздырачак. Моның ише чаралар Казан өчен яңалык түгел. Тик әлеге «Акыл фабрикасы» элеккегеләреннән масштабы, катнашучылар саны һәм форматы белән аерылып тора. Быелгы чарага 30 чит ил, Россиянең 60 регионы һәм Татарстанның бөтен шәһәр-районнарыннан 900дән артык вәкил килер дип көтелә. Биредә 5 төп юнәлеш буенча эшчәнлек алып барылачак. Нәтиҗәсе – татар теле, мәдәнияте, җәмгыяте өчен файдалы проектлар булдыру. Әлеге «Акыл фабрикасы» һәр катнашучы өчен иң истәлекле, файдалы проектларның берсе булыр дигән өметтә калабыз.

**P.S.** *5 нче август көнне «Darelfønyn»дә эшләүче активистларны да «Акыл фабрикасы» мәйданчыкларында күрә алачаксыз.*






12+
DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы:
Р.Р.Садретдинов,
А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 23.06.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.